МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

08.06.2015 № 244

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү Кагыйдәнамәсен раслау турында**

“Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел № 79-ФЗ Федераль законына, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында” 16.01.2003 ел № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законына, “Россия Федерациясенең вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына керү буенча конкурс турында” 01.02.2005 ел № 112 Россия Федерациясе Президенты Указына туры китереп, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урыннарга керү өчен югары сыйфатлы сайланыш һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) эффектив кадрлар резервын формалаштыру максаты белән б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү турында Кагыйдәнамәне (алга таба – Кагыйдәнамә) расларга.

2. Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү буенча конкурсларны һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең урынына өчен кадрлар резервына керү хакы буенча конкурсларны оештырып үткәргән вакытта Татарстан Республикасы ГТХМ ның конкурс комиссиясенә бу Кагыйдәнамәгә таянып эшләргә.

3. Боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ ның министр урынбасарларына, структура аппараты бүлекләре җитәкчеләренә һәм дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә җиткерергә.

4. Бу боерыкны башкару буенча контрольне министр урынбасары Н.В. Суржкога йөкләргә.

Министр Р.Җ. Хәбибуллин

08.06.2015 ел № 244
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгына Кушымта

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү Кагыйдәнамәсе**

1. Төп кагыйдәләр

1.1. Биредәге Кагыйдәнамә Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны (алга таба – конкурс) үткәрү тәртибен һәм шартларын, шулай да Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) конкурсны үткәрү методикасын билгеләп куя.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә тиң конституцион рөхсәт хакы, шулай да Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә хезмәттәге үсеш хакы белән тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы ГТХМ да конкурс "Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында" 27.07.2004 ел № 79-ФЗ Федераль законының 22 нче мәкаләсе һәм "Россия Федерациясенең вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына керү буенча конкурс турында" 01.02.2005 ел № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс Татарстан Республикасы ГТХМ да Татарстан Республикасы вакант гражданлык хезмәте урынына керү өчен дәгъвачылырның профессиональ дәрәҗәсен билгеләүдән, бу урынга билгеләп куелган квалификацион таләпләргә туры килүдән гыйбарәт.

1.3. Конкурс вакант гражданлык хезмәте урыны булган структура булекчәсе җитәкчесенең дәлилләнгән язу мөрәҗәгать нигезендә, кадрлар хезмәте белән ризаланып, Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры (алга таба – министр) карары белән игълан ителә (биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 1).

1.4. Конкурс Татарстан Республикасы ГТХМ да үткәрелми:

билгеле вакытка дәүләт гражданлык хезмәте урынына "җитәкчеләр" һәм "ярдәмчеләр (киңәшчеләр)" категорияләренең вәкаләте билгеләнгәндә;

ашыгыч хезмәт контрактын төзегәндә;

"Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында" 27.07.2004 ел № 79-ФЗ Федераль законының 31 нче мәкаләсенең 1 нче бүлегендә һәм 60.1 нең 9 нчы бүлегендә алдан исәпкә алынган очракларда гражданлык хезмәткәрен башка гражданлык хезмәте урынына билгеләгәндә;

гражданлык хезмәте урынына гражданлык хезмәте кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) билгеләгәндә.

1.5. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

урындагы вазифаларны башкару дәүләт сере белән бәйле Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән расланган урыннар исемлеге буенча гражданлык хезмәтенең аерым урыннарына билгеләгәндә;

министр карары буенча гражданлык хезмәтенең кече урыннарына туры килә торган гражданлык хезмәте урынына билгеләгәндә.

1.6. Конкурс түбәндәге максатлар белән үткәрелә:

сәләт һәм профессиональ белемгә туры килә торган Россия Федерациясе гражданнарының гражданлык хезмәтенә тиң рөхсәт, шулай да конкурс нигезендә гражданлык хезмәткәрләренә урындагы үсеш хакын тәэмин итер өчен;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган таләпләргә туры килә торган кандидатларның гомуми санышнан вакант гражданлык хезмәте урынына күбрәк килешә торган кандидатларны сайлар өчен;

Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар резервын формалаштырыр өчен.

1.7. Конкурсларны үткәргәндә чишелә торган мәсьәләләр:

конкурс мәсьәләләре һәм гамәлләре үткәндә бөтен кандидатлар өчен тиң шартларны тәэмин итү;

объектив профессиональ мөһим критерийләр нигезендә кандидатларны сынау;

конкурс гамәлләрендә алынган объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән вакант гражданлык хезмәте урынына таләпләренә туры килә торган конкурс катнашучылары арасында шәхесләрне билгеләп табу.

## 2. Конкурс комиссиясенең формалашу һәм эш тәртибе

2.1. “Россия Федерациясенең вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына керү буенча конкурс турында” 01.02.2005 ел № 112 Россия Федерациясе Президенты Указына туры китереп, Татарстан Республикасы ГТХМ да даими эшли торган конкурс комиссиясе корыла. Аның составы Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән раслана. Комиссия составына кергән урындагы шәхесләрнең персональ составы үзгәргәндә Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән туры килгән үзгәрешләр языла.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисе конкурс комиссиясе эшен җитәкләп бара, утырышны үткәрү көнен билгели һәм аның көн тәртибен раслый, конкурс комиссиясе утырышларында рәислек итә һәм туры килгән документларга кул куя. Конкурс комиссиясе рәисе булмаган вакытта аның хокукларын һәм вазифаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре конкурс комиссиясе эшен тәэмин итә (регистрация, гаризалар кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе беркетмәләрен алып бару, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү).

2.4. Татарстан Республикасы ГТХМ конкурс комиссиясе составына министр урынбасарлары, эшләрне идарә итүче, кадрлар һәм юридик хезмәт вәкилләре, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар

департаменты вәкиле, вакант гражданлык хезмәте урынына керү конкурсы үткәрелә торган структура бүлекчәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы ГТХМ карамагындагы Җәмәгать советы вәкилләре, шулай да Татарстан Республикасы ГТХМ соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты чакыра торган, бәйсез экспертлар буларак, фәнни, белем бирү һәм башка оешмаларның вәкилләре – экспертларның персональ мәгълүматы күрсәтелмичә, гражданлык хезмәте сораулары буенча белгечләр керә.

Татарстан Республикасы ГТХМ карамагындагы Җәмәгать советы вәкилләренең кандидатуралары конкурс комиссиясе составына кертелер өчен бу совет белән министр соравы буенча күрсәтелә.

Татарстан Республикасы ГТХМ карамагындагы Җәмәгать советы вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан бер өлеш дүрттән ким булмаска тиеш.

2.5. Дәүләт сереннән торган мәгълүматны куллану белән бәйле урындагы вазифаларны башкара торган вакант гражданлык хезмәтенә керү буенча конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе составы, дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнарының кагыйдәнамәләре исәпкә алынып, формалаштырыла.

2.6. Кабул ителә торган конкурс комиссиясе карарларына тәэсир итә торган кызыксыну бәхәсләре килеп чыгу мөмкинлеген булдырмас итеп конкурс комиссиясе составы формалаштырыла.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы вакант гражданлык хезмәте урынына керер өчен (кадрлар резервына керер өчен) ике кандидаттан ким булмыйча үткәрелә һәм, аның әгъзалары ике өлеш өчтән ким булмаса, хокуклы дип санала. Татарстан Республикасы ГТХМ да гражданлык хезмәте урыннарына керә торган комиссия әгъзаларыннан гына торган конкурс комиссиясе утырышын үкәрергә рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү көнен, урынын, вакытын һәм тәртибен, кандидатларны сынау ысулларын билгели;

вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына кермәкче булган гражданнарны (гражданлык хезмәткәрләрен) конкурс үткәрү шартлары турында белдереп тора һәм аларга киңәш бирә;

кандидатлардан килгән сораулар буенча конкурс документларын бирә;

вакант дәүләт гражданлык хезмәте урыны кандидатлары биргән документларны тикшергәннән соң конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларга билгеләп куелган таләпләргә туры килү сынавын үткәрә;

конкурсны нәтиҗәләү, кандидат конкурс җиңүчесе булып чыккан турында карар итә, аны кадрлар резервына кертер өчен тәкъдим итә.

2.9. Конкурс комиссиясе карары кандидат булмаганда кабул ителә һәм аны вакант гражданлык хезмәте урынына билгеләү яисә (аның ризалыгыннан) кадрлар резервына кертү яки моны кире кагу нигезе булыр.

2.10. конкурс комиссиясенең табыш бирү нәтиҗәләрен конкурс комиссиясе беркетмәсе рәсмиләштерә. Аңа утырышта катнашкан комиссиянең рәисе, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары кулы куела. Шул ук вакытта конкурс

комиссиясе карарында гражданлык хезмәте урынына беренче тапкыр кабул ителгән яисә Татарстан Республикасы ГТХМ да гражданлык хезмәте урынының башка группасы яисә категориясенә күчергән вакытта гражданин өчен сынап карау дәвамлыгы буенча тәкъдим бирелергә мөмкин.

2.11. Конкурсны турыдан-туры үткәрү буенча оештыруны һәм тәэмин итүне, конкурс комиссиясе эшен Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар хезмәте башкара.

## 3. Конкурс катнашучылары

3.1. 18 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданнарына, Россия Федерациясе дәүләт телен белә торган һәм дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган вакант урынга (кадрлар резервына кертүгә) квалификацион таләпләренә туры килә торган гражданнарга  конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

Гражданлык хезмәткәре, конкурс үткәрү вакытында ул нинди урында булганга карамастан, гомуми нигезләр буенча конкурста катнашырга хаклы.

3.2. Татарстан Республикасы ГТХМ ның гражданлык хезмәте вакант урынына керүче (кадрлар резервына керүче) кандидатларның таләпләренә туры килә торган һәм билгеләп куелган вакыт эчендә бөтен кирәк документларны биргән гражданнарга конкурста катнашырга рөхсәт ителә.

3.3. Гражданинга (гражданлык хезмәткәренә), ул вакант гражданлык хезмәте урынының квалификацион таләпләренә туры килмәсә, шулай да гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен дәүләт гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләп куелган чикләмәләр аркасында, конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

3.4. Вакант дәүләт гражданлык урынына кандидатларның квалификацион таләпләре дәүләт гражданлык хезмәте турында федераль һәм республика законнары белән билгеләп куела һәм Татарстан Республикасы ГТХМ боерыгы белән раслана.

3.5. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины дәүләт органына бирә:

а) шәхси гаризаны (биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 2);

б) 26.05.2005 ел № 667-р Россия Федерациясе Хөкүмәте Боерыгы белән расланган форма буенча 4 х 6 фотография белән үз кулы белән тутырылган һәм имза куелган анкетаны;

в) паспорт яисә аны алмаштыра торган документ күчермәсен (туры килә торган документ конкурска килүгә шәхсән күрсәтелә);

г) кирәк профессиональ белем, квалификация һәм эш стажын раслый торган документларны:

нотариаль рәвештә яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте белән расланган  хезмәт кенәгәсе күчермәсен (хезмәт (эш) беренче тапкыр башкарылган очраклардан тыш) яисә гражданин эшләгәнне (хезмәт иткәнне) раслый торган башка документларны;

белем һәм квалификация турында документлар күчермәсен, шулай да гражданин теләге буенча өстәмә профессиональ белем нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрү яисә алуны раслый торган документлар, нотариаль рәвештә яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте белән расланган гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем үзләштерү турында документлар күчермәсен;

д) гражданинда гражданлык хезмәтенә керергә яисә аны башкарырга комачаулый торган авыру булмаганы турында документ;

е) “Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында” 27.07.2004 ел № 79-ФЗ Федераль законы, башка федераль законнары, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән алдан исәпкә алынган башка документларны.

3.6. Конкурста катнашырга теләк биргән Татарстан Республикасы ГТХМ ның гражданлык хезмәткәре Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министры исеменә гариза бирә.

3.7. Урындагы вазифаларны башкару буенча урын дәүләт яисә закон саклый торган башка серле мәгълүмат куллануы белән бәйле булса, гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгыннан гражданлык хезмәте урынына кермәкче булган гражданин (гражданлык хезмәткәре) өчен мондый мәгълүматка рөхсәт бирүне рәсмиләштерү гамәле үткәрелә.

Гражданин яллаучы исеменә китергән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш.

Гражданлык хезмәткәре китергән мәгълүматларның дөреслеге тикшерелүе вакант гражданлык хезмәте урынына керү конкурсында катнашкан вакант гражданлык хезмәте урыны гражданлык хезмәте урыннарының югары группасына туры килгән очракта гына башкарыла.

3.8. Конкурста катнашыр өчен документларны кандидатлар Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар хезмәтенә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталы Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтында һәм “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системада конкурс үткәрү турында информацион хәбәр урнаштырылган вакыттан 21 көн эчендә китерә.

3.9. Документларны нигезле сәбәпсез вакытында китермәү, аларны тулы күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен үтәп китермәү аларны гражданиннан кабул итүне кире кагырга нигез булыр.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргән вакытта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларны сынау ысулларыннан корылган конкурс мәсьәләләре һәм гамәлләре кулланыла.

4.2. Кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларны сынау критерийләре Татарстан Республикасы ГТХМ гражданлык хезмәте урыннарының квалификацион таләпләре нигезендә корылган.

Конкурс нинди урыннарның группасына һәм категориясенә үткәрелүгә карап, конкурста катнашучыларны сынау критерийләре һәм сайланган сынау методлары үзгәрелергә мөмкин.

Якынча исемлек һәм конкурста катнашучыларның сынау критерийләренең кыска тасвиры биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 3 китерелгән.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар конкурс мәсьәләләрен чишү һәм конкурс гамәлләрен үтү нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

4.4. Конкурс ике этап аша үтә.

4.4.1. Беренче этапта кадрлар хезмәте оештыра:

Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтында һәм “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системада конкурс үткәрү турында түбәндәгеләрдән торган мәгълүматны хәзерләү һәм урнаштыруны: вакант гражданлык хезмәте урынының исеме, бу урынга кермәкче булган дәгъвачыга таләпләр, гражданлык хезмәтен башкару шартлары, документларны кабул итү урыны һәм вакыты, билгеләнгән документларны кайсы вакытка кадәрь кабул ителү, конкурсның уйланылган үткәрү көне, аның үткәрү урыны һәм тәртибе, башка информацион материаллар. Конкурста катнашыр өчен документларны кабул итү турында белдерү һәм конкурс турында мәгълүмат шулай ук периодик матбугат басмасында бастырылырга мөмкин;

гражданин (гражданлык хезмәткәре) китергән документлар тикшерүен;

гражданин (гражданлык хезмәткәре) квалификацион таләпләргә (профессиональ белем дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (гражданлык хезмәтенең башка төрләренең) стажы яисә белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибәсе) хәзерләнү юнәлеше, урындагы вазифаларны башкарыр өчен кирәк профессиональ белем һәм күнекмә) туры килү тикшерүен.

конкурсның беренче этабы кабул итү турында белдерү урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән иртәрәк түгел тәмамлана.

4.4.2. Тикшерү вакытында, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокук актларына туры китереп, гражданинга гражданлык хезмәтенә керергә комачаулый торган шартларны тапканда ул конкурста катнашуга кире кагу сәбәпләре турында язу формасында министрдан хәбәр ала.

4.4.3. Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәгән вакант гражданлык хезмәте урынына керү (кадрлар резервына керү) дәгъвачысы Россия Федерациясе законнарына туры китереп бу карар турында шикаять бирергә хаклы.

4.4.4. Билгеләп куелган квалификацион таләпләргә туры килә торган кандидатларның саны бер вакант гражданлык хезмәте урынына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте урынына) икедән ким булмау конкурсның беренче этапның тәмамлану шарты булыр. Бу кандидатларны алга таба сайлауны башкарырга мөмкинлек бирә.

Кандидатлар булмаган очракта яисә урынның квалификацион таләпләренә туры килә торган бер генә кандидат булган вакытта конкурс булдырылмаган дип таныла. Бу очракта бердән бер кандидат кандидатларның кирәк саны булмаган аркасында конкурс комиссиясе карары буенча конкурс булдырылмаган дип танылганы турында язу рәвешендә белдерелә.

4.4.5. Билгеләп куелган таләпләргә иң югары дәрәҗәдә туры килә торган һәм конкурста алга таба катнашырга тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге төзелүе турында конкурс комиссиясе рәисе белән раслана торган конкурс комиссиясенең карары беренче этап нәтиҗәсе булыр.

Кадрлар хезмәте конкурсның икенче этабы башланганына кадәрь 15 көн алдан конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гражданнарга (гражданлык хезмәткәрләренә) конкурсны үткәрү көне, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

4.4.6. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр конкурсның икенче этабын үткәрү көне, вакыты һәм урыны турында карар кабул иткәннән соң конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын уздыра.

4.4.7. Конкурсның икенче этабында кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын сынар өчен түбәндәге ысуллар кулланылырга мөмкин:

язу тест яисә махсуслаштырылган компьютер тестын үткәрү;

анкета тутыру;

психологик тест;

аналитик эш (реферат, әсәр) язу;

практик биремнәр;

индивидуаль әңгәмә.

Аталган ысулларның барысын да куллану мәҗбүри түгел. Конкурсны үткәргән вакытта аларның кирәге, шулай да куллану тәртибе конкурс комиссиясе белән билгеләнә. Ысулларның берсесе белән (мәсәлән, индивидуаль әңгәмә белән) вакант урын конкурсында җиңүче табылса, конкурсны тәмамланган дип санарга ярый.

4.4.8. Татарстан Республикасы ГТХМ ның эш юнәлешләре буенча норматив хокук актлары һәм конкурс гамәлләрен үтүгә хәзерләнер өчен гомуми сораулар исемлеге кандидатларга танышыр өчен аларны үткәрүгә кадәрь 3 эш көненнән соңрак булмыйча ачык булырга тиеш.

4.4.9. Кандидатларның дәүләт гражданлык хезмәтенең билгеле вакант урынына тест үтүе кадрлар хезмәте белән әзерләнгән дәүләт хезмәте турында законнарны белү буенча бердәм теоретик сораулар исемлеге буенча һәм вакант урыны булган структура бүлегенең эш юнәлеше буенча теоретик һәм практик сораулар исемлеге буенча үткәрелергә мөмкин. Шулай да махсуслаштырылган компьютер тесты кулланылырга мөмкин.

Тест 30 сораудан артык торырга тиеш түгел.

Дөрес җаваплар тигез санда булган вакытта катнашучыларга җавап бирүгә вакыт санап башлау белән өстәмә тестлар бирелә.

Дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына булган кандидатларга бертөрле мәсьәләләр бирелә һәм җавап бирү өчен аларның бертигез вакытлары бар.

4.4.10. Аналитик эшне (рефератны) язып өчен дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынын дәгъвалый торган кандидатлар өчен урын буенча урындагы вазифаларны һәм вәкаләтне башкару белән бәйле сораулар кулланыла. Аналитик эшләрнең (рефератларның) темалары вакант урыны булган министрлыкның структура бүлеге билгели.

4.4.11. Кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын сынаган вакытта конкурс комиссиясе гражданлык хезмәте урынына туры килә торган квалификацион таләпләрдән һәм бу урын буенча урындагы регламентның башка кагыйдәләреннән, шулай да дәүләт гражданлык хезмәте турында биредәге Кагыйдәнамә һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләп куелган башка кагыйдәләрдән чыгып эш итә.

4.4.12. Комиссия әгъзалары кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын кадрлар хезмәте белән һәр конкурс өчен әзерләнә торган билгеләү кәгазьләрендә (биредәге Кагыйдәнамәгә кушымта № 4) билгеләп куялар.

Турыдан-туры конкурс башлануы алдыннан конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче конкурс комиссиясе әгъзалары өчен конкурсны уткәрү, билгеләр кую тәртибе, конкурс комиссиясе әгъзаларының хокуклары һәм вазифалары турында инструктаж үткәрә.

4.4.14. Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы конкурста бөтен катнашучыларның сынау кәгазьләрен конкурс комиссиясе секретареннән ала һәм билгеле бер кандидатны караган вакытта һәм күрсәткеч (“туры килә”, “билгеле белем алса, туры киләчәк” һәм “туры килми”) буенча туры килә торган баганада билге куеп ул белдерелгән таләпләргә туры килү дәрәҗәсен билгели. Һәр баганада җыелган билгеләр саны буенча комиссия әгъзасы сынау кәгазендә туры килгән юлны тутырып кандидат биредәге урынга туры килгәне яисә туры килмәгәне турында нәтиҗә ясый. Аннан соң һәр комиссия члены биредәге кандидат буенча, туры килгән баганада сайланган вариантны билгеләп, сынау кәгазендә нәтиҗә ясый (кандидатны урынга билгеләүне, кадрлар резервына кертүне тәкъдим итергә яисә кандидатны бу урынга билгеләүне кире кагырга). Кандидат туры килгәне яисә туры килмәгәне турында нәтиҗәне комиссия әгъзалары конкурс катнашучыларының сынау критерийләрен исәпкә алып ясыйлар (дәүләт хезмәте культурасына, профессиональ компетентлыкка, шәхси һәм эш итү белән бәйле сыйфатларга туры килү). Сынау кәгазьләре тутырылганнан соң һәм конкурс комиссиясе әгъзасы сынау кәгазьләренә имза куя һәм конкурс комиссиясе секретаренә тапшыра.

4.5. Конкурсны йомгаклар өчен һәм кандидатны дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына кертү турында карарны кабул итү өчен түбәндәге нигезләр булыр:

бөтен конкурс гамәлләрен үтү нәтиҗәләре буенча кандидатлар алган йомгак билгеләр;

сынау кәгазендә язып куелган һәм конкурс катнашучыларын сынау критерийләрен куллануда нигезләнгән һәр конкурс комиссиясе әгъзасының нәтиҗәсе;

кандидатлар белән әңгәмә нәтиҗәләре буенча структура бүлегенең вакант гражданлык хезмәте урынына дәгъвалый торган кандидатлар турында структура бүлегенең җитәкчесе фикере.

4.6. Конкурсны үткәрү нәтиҗәсе буларак, вакант гражданлык хезмәте урынына (кадрлар резервына керү) буенча бөтен кирәкле таләпләргә туры килә торган кандидатлар табылмаган булса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар итергә яисә яңа конкурсны үткәрү турында тәкъдим кертергә хаклы.

4.7. Конкурс комиссиясе утырышының гомуми членнар саны ике өлеш өчтән ким булмаса, ул хокуклы дип исәпләнә. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта булган членнарның гади күпчелеге белән ачык сайлаулары белән кабул ителә.

4.8. Ике һәм икедән артык конкурс катнашучылары белән җыелган башка бертигез күрсәткечләр булганда конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булыр.

4.9. Конкурсны үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе күренешендә рәсмиләштерелгән конкурс комиссиясе карары кабул ителә һәм конкурс комиссиясен рәислек итүченең, секретарьнең һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының имзалары куела.

4.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен вакант гражданлык хезмәте урынына урнаштыру турында министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Вакант гражданлык хезмәтенә керү буенча конкурста җиңмәгән, ләкин аның профессиональ һәм шәхси сыйфатлары югары билгеләр алган кандидатны конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы ГТХМ кадрлар резервына кертү турында тәкъдим сыйфатында булган карарны кабул итергә хаклы.

Кандидат ризалыгыннан ул нинди вакант гражданлык хезмәте урынының группасына туры килгән шул ук гражданлык хезмәте урыннарына керер өчен кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) – конкурс җиңүчесен кадрлар резервына кертү Татарстан Республикасы ГТХМ ның боерыгы күчермәсен гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә салу белән Татарстан Республикасы ГТХМ ның боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.11. Вакант гражданлык хезмәте урынына (кадрлар резервына) керүче кандидат Россия Федерациясе законнарына туры китереп конкурс комиссиясе карарына шикаять бирергә хаклы.

4.12. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрләр конкурс катнашучыларына язу формасында ул тәмамланган көннән алып 7 көн эчендә җибәрелә. конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук билгеләнгән вакыт эчендә Татарстан Республикасы ГТХМ ның рәсми сайтында һәм “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт информацион системада урнаштырыла.

4.13. Конкурста катнашырга рөхсәт бирелмәгән вакант гражданлык хезмәте урынына кермәкче дәгъвачыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язу гаризасы буенча конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә аларга кире кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт үткәнче документлар Татарстан Республикасы ГТХМ ның архивында саклана, аннан соң алар бетерелергә тиеш була.

4.14. Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурсны үткәрү урынына һәм кире бару, торак бүлмәне яллау, яшәү, элемтә чараларының уңайлыклары белән куллану һәм башкалар) кандидатлар белән үз акчага башкарыла.

2015 елның 8 нче июньнән № 244
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган
Кагыйдәнамәгә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы ГО
эшләре һәм ГТХ министрына
______________________________
(инициаллар, фамилия)

Рәсми язу

Конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына кертү) конкурсын белдерү үтенече белән Сезгә мөрәҗәгать итәм.
________________________________________________________________________________
(бүлек исеме)
________________________________________________________________________________
(урын исеме)

Бу урынга кермәкче булган дәгъвачыга түбәндәге таләпләр куела:
белем буенча - ______________________________________________________________
дәүләт хезмәте стажы һәм эш тәҗрибәсе буенча - ____________________________
күнекмә һәм белемнәр буенча-_________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Бүлек башлыгы ________________________________
(дата) (имза, имзаны ачыклау)

Ризаланган:

Идарә башлыгы
Министр урынбасары

2015 елның 8 нче июньнән № 244
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган
Кагыйдәнамәгә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы ГО
эшләре һәм ГТХ министрына

______________________________
(инициаллар, фамилия)

______________________________
(фамилия, исем, ата исеме)

белем ________________________
(дәрәҗә, уку йорты, бетерү елы)

______________________________

адресы буенча яши торган
тел. __________________________
(эш, өй, кесә телефоны)

e-mail _________________________

Гариза

Миңа Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте кадрлар резервына керү хокукына) буенча конкурста катнашырга рөхсәт бирергә сорыйм.

______________________________________________________________________
(бүлек исеме)

______________________________________________________________________
(урын исеме)

“Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” 27.01.2004 ел № 79-ФЗ Федераль законы, “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында” 16.01.2003 ел № 3-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гражданлык хезмәте турында башка норматив хокук актлары, Татарстан Республикасы ГТХМ да дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына керү (кадрлар резервына керү) буенча конкурсны үткәрү Кагыйдәнамәсе, шул исәптән аталган урынга куелган квалификацион таләпләр белән таныштым.

Дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер булган мәгълүматларга рәхсәтне расмиләштерү гамәлен үткәрүе белән риза булам.

e-mail яисә язылган кесә телефоны аша конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында белдерү белән ризамын.

Гаризага терким: (теркәлгән документларны санап чыгарга).

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

| ________ | ____________ | __________________ |
|---|---|---|
| Дата | Имза | Имзаны ачыклау |

2015 елның 8 нче июньнән № 244
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган
Кагыйдәнамәгә 3 нче кушымта

Конкурс катнашучыларын сынау критерийләре

## I. Дәүләт хезмәте культурасына туры килү

1.1. Профессиональ дәрт

Дәүләт хезмәтендә үзен профессиональ тормышка ашыру омтылышы, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәт үсешенә юнәлеш.

1.2. Гражданлык карашы

Эштә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законлылыкны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү принципларын үтәү.

1.3. Профессиональ карашның активлылыгы

Куелган мәсьәләләрне чишкән вакытта инициативаны күрсәтергә тырышу; мөмкин булганча иң яхшы нәтиҗәне ирешер өчен җитди көчләрне куярга әзер булу; физик һәм эмоциональ йөкләнеш шартларында нәтиҗәле эш башкару сәләте (стресска каршы тотрыклык).

1.4. Үзлегеннән үсешкә әзер булу

Белемен, осталыгын һәм күнекмәсен камилләштерүгә, белемне киңәйтергә, эргәдәш профессиональ өлкәләрдә белем һәм тәҗрибә алырга даими тырышу.

## II. Дәүләт хезмәткәренең профессиональ компетентлыгы

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә профессиональ белеменең дәрәҗәсе, профиле һәм сыйфаты.

2.2. Профессиональ тәҗрибә

Туры килә торган профессиональ өлкәдә эшнең дәвамлыгы һәм үзенчәлекләре; профессиональ эштә билгеле нәтиҗәләргә ирешү; карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус профессиональ белем, осталык һәм күнекмә

Туры килә торган өлкәдә функциональ вазифаларны эффектив башкарырга мөмкинлек бирә торган профессиональ белем дәрәҗәсе; профессиональ эшне регламентлаштыра торган Россия Федерациясе законнарын белү; заманча профессиональ технологияләрне белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмә

Профессиональ эшнең гомуми нәтиҗәлеген арттыра торган күнекмә дәрәҗәсе (компьютерны куллану, гомуми дөрес язу, чит телләрне белү һ. б. ш.).

## III. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең шәхси һәм эш итү сыйфатлары

3.1. Аналитик сәләтләр

Мәгълүматны анализларга һәм структураларга таләп итә торган авыр мәсьәләләрне чишергә мөмкинлек бирә торган фикерләүнең системлык һәм сизгерлек дәрәҗәсе.

3.2. Эффектив аралашу күнекмәсе

Эш буенча аралашу этикасын үтәү; дәлилле рәвештә үз фикерен яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте; эш сөйләшүләрен алып бару күнекмәсе.

3.3. Җаваплылык

Карарларны кабул иткәндә төплелек һәм мөстәкыйльлек; нәтиҗәгә ирешкәндә үзенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булу.

3.4. Оештыру сәләтләре

Үз эшен һәм кул астында эшләүчеләрнең эшен эффектив планлаштырганга, функцияләрне, вәкаләтне һәм җаваплылыкны эффектив бүлгәнгә күрә нәтиҗәләргә ирешергә белү.

2015 елның 8 нче июньнән № 244
Татарстан Республикасы ГТХМ
боерыгы белән расланган
Кагыйдәнамәгә 4 нче кушымта

*Татарстан Республикасы вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына керү буенча кандидатның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын*

# СЫНАУ КӘГАЗЕ

«____________________________________________________________»
(вакант урынның исеме)

______________________________________________________________
(кандидатның фамилиясе, исеме, ата исеме)

| N т/б | Кандидат сыйфатларының билгеләр күрсәткече | Кандидат квалификациясе куела торган таләпләргә туры килү дрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|
| | | туры килә | билгеле белем алса, туры киләчәк | туры килми |
| ***Кандидат күрсәткән документларны анализлау нигезендә кандидатны билгеләү*** | | | | |
| 1 | Профессиональ белем дәрәҗәсе | | | |
| 2 | Квалификацияне күтәрү һәм профессиональ укытуны яңадан үтү | | | |
| 3 | Белгечлек буенча эш стажы һәм тәҗрибәсе | | | |
| ***Конкурс гамәлләре нигезендә кандидатны билгеләү*** | | | | |
| 4 | Дәүләт гражданлык хезмәте турында законнарны белү дәрәҗәсе | | | |
| 5 | Бүлек эше юнәлеше буенча законнарны белү дәрәҗәсе | | | |
| 6 | Психологик тест үтү (үткәргән очракта) | | | |
| 7 | Профессиональ, эш һәм шәхси сыйфатлар дәрәҗәсе | | | |
| 8 | Керергә планлаштырыла торган урын буенча эшне белү | | | |
| 9 | Фикерләрен телдән һәм язма рәвештә аңлату сәләте | | | |
| 10 | **Конкурс комиссиясе утырышында әңгәмә нәтиҗәләре буенча кандидатны билгеләү** | вакант урынга туры килә | билгеле белем алса, вакант урынга туры киләчәк | вакант урынга туры килми |
| | | | | |
| | **Нәтиҗә** | Кандидатка вакант дәүләт гражданлык хезмәте урынына билгеләүне тәкъдим итергә | Кандидатка аны Татарстан Республикасы ГТХМ ның кадрлар резервына кертергә тәкъдим итергә | Кандидатны дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант урынына билгеләүне кире кагырга |
| | | | | |

**Конкурс комиссиясе рәисе (әгъзасы)** ______________________________________
(имза, имзаны ачыклау)